12+

Акмамык

Ак-Ламык

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

Акмамык
Ак-Ламык

Төрекмән халык әкияте
Туркменская народная сказка

Казан • Татарстан китап нәшрияты • 2016
Казань • Татарское книжное издательство • 2016

УДК 821.512.145:821.161.1-34
ББК 84(5 Турк)
А41

Рәссамы *Светлана Ибраһимова*
Художник *Светлана Ибрагимова*

Төрекмәнчәдән татарчага *Айсылу Галиева* тәрҗемәсе
Перевод с туркменского на татарский язык *Айсылу Галиевой*

Татарчадан русчага *Энҗе Хөснетдинова* тәрҗемәсе
Перевод с татарского на русский язык *Энже Хуснутдиновой*

А41 **Акмамык** : төрекмән халык әкияте = Ак-Памык : туркменская народная сказка / [төрекмәнчәдән татарчага – Айсылу Галиева, татарчадан русчага Энҗе Хөснетдинова тәрҗемәсе]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. – 38 б.
ISBN 978-5-298-03174-5

Әлеге төрекмән әкиятендә батыр йөрәкле Акмамык исемле кызның туганнарын эзләүдәге михнәтле авыр юлы тасвирлана. Мәхәббәт һәм нәфрәт, яхшылык һәм явызлык, эчкерсезлек һәм мәкер көрәше әкияттә ничек чишелеш таба – боларны белер өчен әсәрне, һичшиксез, укып чыгарга кирәк.

Героиней этой туркменской сказки является девушка с храбрым сердцем по имени Ак-Памык. В сказке описывается её хождение по мукам в поиске братьев. Битва братьев с Дивом, встреча Ак-Памык с верблюдицей-людоедом, предательство любимого кота... Захватывающий сюжет сказки никого не оставит равнодушным.

УДК 821.512.145:821.161.1-34
ББК 84(5 Турк)

ISBN 978-5-298-03174-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Татарское книжное издательство, 2016

АКМАМЫК

Борын-борын заманда ир белән хатын яшәгән, ди. Боларның җиде уллары булган, ә кызлары юк икән. Бервакыт әниләре бәбигә авырый башлаган. Малайлар ауга җыенганнар, аталарына:

– Сеңлебез туса, капка кыегына курчак утыртырсыз, энебез булса, ук-җәя асып куярсыз, – дигәннәр.

Боларның кызлары туа. Аталары, сөйләшенгәнчә, капка кыегына курчак чыгарып утырта. Әмма күршеләре курчакны ук-җәя белән алыштырып куялар, ди. Егетләр, аудан кайтышлый, ук-җәягә күзләре төшеп: «Ходай безгә сеңел бирмәгән икән», – дип үпкәләп, бер тау куышына барып урнашып, ау аулап көн күрә башлыйлар.

Болар бу тауда калып торсын, без аларның сеңелләренә күчик.

Ата-әнкәсе кызчыкка Акмамык дип исем кушалар. Уллары гына күренми. Бер көн көтәләр – юк, бер ай көтәләр – юк, бер ел көтәләр – уллары гына кайтмый да кайтмый икән. Алардан бер хәбәр дә булмагач, тәмам өметләрен өзәләр.

Ай кичеп, ел кичеп, кыз ун яшенә җитә. Беркөнне күршеләре, өмә уздырырга җыенып, Акмамыкны әнисеннән сорый керә:

– Кызыңны өмәгә җибәрче, – ди.

– Үзе риза булса керсен, үзенә әйт, – дип, әнисе риза була.

Акмамык бик шатланып өмәгә кереп китә. Өмәгә килгән киленнәрнең берсе:

– Кемнең ир туганы бар, түргә үтсен, ир туганы булмаганнар көлгә утырсын, – дип сүз башлый.

Акмамык та көлдә утырган кызлар янына килеп чүгәли. Бер карчык Акмамыкка:

– Бәй, киегем, син түргәрәк уз, – ди икән.

– И-и, инәкәй, минем ир туганнарым юк бит.

– Ай йөзе кара, бер туганы булганнар да түргә узган, синең җиде абзаң бар бит! Әйдә, уз, түргәрәк уз.

– Шушы яшемә җитеп, абзаларым барын белми идем, – ди кыз.



Аңа кортка:

– Киегем, атаң-анаң картайды инде, туганнарыңны эзләп тә арыдылар. Әйтсәк, син дә абзаларыңны эзләп китәрсең дип куркалар. Туганнарың тау куышында яшиләр. Мин сиңа туганнарыңның барлыгын әйттерергә өйрәтәм. Кайткач, әнкәңә, куырма куырып бир әле, диген. Куырып бирер, ләкин син алма, үз кулың белән бир, диген. Казанның өстеннән үз кулы белән алып биргәндә беләгеннән кысып тотып алсаң әйтер, башкача әйтмәс, – дип өйрәткән.

Акмамык, өмәдән кайткач:

– Ай, әнием, мин авырыйм, ахры, – ди.

– Балам, ни бирим, ашыйсы-эчәсе килгән нәрсәң юкмы? – дип сорый әнисе.

Акмамык аңа:

– Әнием, куырма куырып бир, авыртуым шулай басылмасмы, – ди икән.

Әнисе куырып бетергәч, куырманы кашык белән кызына суза, ләкин Акмамык аңа:

– Юк, үз кулың белән бир, – ди.

Әнисе мескен үз кулы белән биргәндә, Акмамык аның кулын каты итеп тотып ала.

Әнисе исә:

– Вай, кулым янды, – дип кычкыра икән.

– Әнием, минем агаларым бармы, юкмы, әйт? – дип сорый Акмамык.



Әнкәсе, чыдый алмыйча:

– Бар, әмма алар син туган көнне өйдән чыгып киттеләр, – ди.

– Ник аларның барлыгын миңа әйтмәдегез?

– Син дә аларны эзләп китәрсең дип курыктык, – ди.

Акмамык, әнисенең кулын җибәреп:

– Мин агаларымны эзләп китәм, – ди.

– Син үзең генә таба алмассың, – ди әнкәсе, – мин сиңа көлчә пешереп бирермен, шуны тәгәрәтеп, артыннан барсаң табарсың.

Акмамыкка әнкәсе көлчә әвәләп бирә. Көлчә тәгәрәп китә, көлчә артыннан Акмамык йөгерә икән, Акмамык артыннан аның песие чаба, ди. Күпме тәгәрәгәндер, күпме чапканнардыр – билгесез, берзаман алар тау куышына килеп җитәләр. Килеп керсәләр, тау куышы пычрак керләр белән тулган, күп итеп ит киптерергә эленгән. Акмамык киемнәрнең юасын юып, ашарга әзерләп, табын җәеп куя. Агаларының кайткан тавышын ишетеп, бер җиргә кереп яшеренә. Туганнары килеп керсәләр, үз куышларын танымыйлар: ашарга пешерелгән, киемнәр чистартып юылган, ди. Болар бу чиста киемнәрне киенеп, ашап, ял итәргә яталар. Иртән тагын ауга чыгып китәләр, ди. Акмамык янәдән киемнәрне юып, ашарга әзерли дә абыйлары кайтыр вакыт җиткәч, урынына кереп яшеренә. Туганнар, кайткач, җыелып киңәшәләр дә, өйләренә кем килгәнен белер өчен, чиратлашып сакта калырга булалар. Беренче көнне иң олы абыйлары кала. Ауда бик арыган була

шул ул, шундук йоклап та китә. Ул йоклап киткәч, Акмамык яшеренгән урыныннан чыгып, киемнәрне юып, ашарга әзерләгәннән соң, яңадан кача. Энеләре кайтып керсә, тау куышында тәртип, абыйларыннан: «Өйдә кем бар иде?» – дип сорасалар, абыйлары белми: «Йоклап калганмын», – дип, кулларын гына җәйгән.

Ахырында иң кечеләре сакта кала боларның. Ул, йокламас өчен, кул бармагын кисеп, ярасына тоз сибә. Үзе йоклаганга салышып ята инде. Берзаман, Акмамык чыгып эшкә тотынгач, торып:

– Адәмме син, җенме син? Кемлегеңне әйт, – ди.

– Мин адәм дә, җен дә түгел, үз туганыгыз – сеңлегез Акмамык, – дип җавап бирә кыз.

Болар, танышып, калган туганнары кайтканчы эшне бетереп куялар. Аннары кече агасы олыларын каршыларга китә. Үзләре янына сеңелләре килүен белгәч, агалары бик шатлана инде.

Шулай беркөнне Акмамык, өй җыештырганда, бер кишмиш табып алган, ди. «Пес-пес», – дип, песиен чакыра бу. Песие килмәгәч, кишмишне үзе ашап куя.

Бераздан песие, килеп:

– Нигә чакырдың? – дип сорый.

– Бер кишмиш тапкан идем, шуңа чакырдым, – дип җавап бирә Акмамык.

– Кая соң ул?

– Син килмәгәч, үзем ашадым.

– Утыңны сүндерәм, – дип ачуланып, песи утка төкерә башлый.

– Төкермә, мин шакмак белән ут ала белмим, – диеп ялварып, Акмамык песине көчкә туктата.

Икенче тапкыр өй җыештырып йөргәндә, ул бер җиләк табып, тагын песиен чакыра. Песи килмәгәч, янә үзе ашап куя.

Берзаман песи, килеп:

– Мине нигә чакырган идең? – дип сорамасынмы.

– Бер җиләк таптым.

– Кая инде ул?

– Ашадым.

Песи, ачуланып:

– Алай булса, утыңны сүндерәм, – дип, Акмамыкның учагын сүндереп ташлый.

Акмамык таш белән ут чыгармакчы булып тырышса да, учагы кабынмый. Ашарга әзерләргә вакыт аз калып бара, инде нишләргә? Аптыраганнан тышка чыгып караса, бер җирдән төтен чыкканын күрә бу. Акмамык, шул төтенгә төбәп, ут эзләп китә. Барып җитеп, капка төбеннән үк сәлам биреп керсә, өй түрендә бер чал Дию утыра, ди.

Дию Акмамыкны күреп:

– Сәлам бирмәгән булсаң, ике өзеп, бер йотар идем.

Хәзер тимим инде. Кил, кызым, минем башымның бе-
тен кара әле, – ди.

Акмамык бераз Диюнең башын карый да:

– Мин утка дип килгән идем, – ди.

– Әйдә, син итәгеңне тотып тор, – дип, Дию Акмамыкның итәгенә бәләкәй генә бер куз ташлап, өстенә көл сала. Көл өстенә утлы агач кисәге ташлап: – Бар, кызым, – дип, Акмамыкны озатып җибәрә.

Акмамык өенә ашыга, теге кузның итәгенә бәләкәй генә тишек ясап, көлнең коелып баруын сизми. Дию өеннән тау куышына кадәр көл сибелеп кала. Туганнары аудан кайтып, ял иткәч, иртәгесен тагын ауга китәләр. Алар чыгып китү белән, Дию, көл эзеннән тау куышына килеп, Акмамыкны эзләп таба.

– Кызым, ач, – ди икән Дию.

– Юк, ачсам, туганнарым орышырлар, – ди Акмамык.

– Алайса, бер бармагыңны гына булса да ишек астыннан тык, – дип ялвара Дию.

Акмамык бармагын чыгара. Дию бармакны каты итеп тотып энә белән тишә дә канын суырып китеп бара:

– Туганнарыңа әйтсәң, ашап бетерәм, – дип куркыта.

Акмамык куркуыннан туганнарына берни дә әйтми. Дию көн саен килә башлый бит. Акмамык көннән-көн ябыга, сула башлый. Агаларының ни булды дип сорауларына, «берни дә юк» дип җавап бирә.

Туганнары, ничек тә кызның серен ачарга чамалап, беркөнне, ауга бармый калып, тау куышы янына яшеренеп торалар.



Акмамык эшләрен төгәлләп, Дию килер вакыт җиткәч, ишеген эчтән бикләп куя. Кан эчәргә өйрәнеп беткән Дию килеп ишекне кага башлау белән, Акмамыкның абыйлары килеп чыгалар да Диюнең өстенә ташланалар. Диюнең башы: «Күптән-күп кан булаем», – дип тәгәрәп киткән, ди. Акмамыкның абыйлары артыннан куып карасалар да, аны тота алмыйлар. Күпмедер вакыттан соң теге баштан берничә Дию үсеп чыгып, җиде туганны үтереп, сөякләрен генә калдырып китәләр. Акмамыкны гына эзләп таба алмыйлар: ул кәҗә тиресе астында качып кала. Диюләр, аны таба алмыйча, үз өйләренә кайтып китәләр.

Акмамык, диюләр киткәннән соң, яшеренгән урыныннан чыгып, туганнарының сөякләрен киек тиресе белән каплап, атка менеп, шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга кереп, гыйлемле кешеләрдән абыйларын ничек терелтеп булу мөмкинлеген сорашып йөри. Акмамыкка беркем дә ярдәм итә алмый, ахырында ул бер бик карт белекче әби капкасына төртелә.

– Кызым, абыйларыңны Дию үтергән булса, аларны терелтеп булыр булуын, әмма бу бик авыр эш, – ди әби, кызның нишләп йөрүен ишеткәч.

Акмамык:

– Әбекәем, ничек булса да әйт кенә, – дип ялына, ялвара инде.

– Акмая дигән бер дөя бардыр, шуның сөтен туганнарыңның өстенә сипсәң терелерләр. Әмма Акмаяга барып җитә алган кеше юк, күрсә ашап кына бетерер, – ди әби.

Акмамык турсык[1] алып, Акмаяны эзләп юлга кузгала. Ахырында, дала буйлап бара торгач, дөя баласын очрата. Бу Акмаяның бутасы[2] булып чыга бит! Дөя баласы Акмамыкны күреп, уйнаклап аның янына чабып килә. Акмамык дөя баласының муеннарын, башларын кашый, аны сыйлый, аннары үзенең аһ-зарларын сөйли. Дөя баласы:

– Ярар, мин сиңа булышырмын, әгәр анам белсә, икебезне дә тотып ашар, кил, син минем корсак астыма кереп, шунда ябышып бар, – ди.

Акмамык шулай итә дә. Алар килеп җиткәч, Акмая, Акмамыкның исен тоеп:

– Адәм исе килә, – дип, әрле-бирле йөрергә тотынган.

– Анаҗан, монда адәм каян килсен, – дип, әнкәсен тынычландыра дөя баласы, үзе имә башлый. Имгәндә, Акмамыкка да өлеш чыгарып, турсыкны бик җиңел генә тутыралар да кызның аты яшерелгән калкулыкка чабалар. Әмма Акмая да шикләнә бит: баласын күзәтә.

Бозавының корсак астыннан чыгып атка атланган Акмамыкны күреп, дөя дә аларга таба томырыла! Акмамыкны куып тота алмагач, кире әйләнеп кайтып, баласын:

---

[1] *Турсык* – күннән ясалган савыт.

[2] *Бута* – дөя баласы.



– Кара таш булсаң иде, – дип каргый бу.

Дөя баласы шул мизгелдә үк ташка әйләнә.

Акмамык, Акмаяның сөтен кулга төшергәч, тау куышына әйләнеп кайта. Абыйларының сөякләрен җыеп тезеп сала бу, бары тик бер абыйсының сырт сөяген таба алмый. Диюләр әллә чәйнәп үк ташлаган, бер җирдә дә юк, ди. Булганнарын рәтләп, өсләренә сөт сибеп, киез каплый. Бераз вакыттан абыйлары, төчкереп:

– Озак йоклаганбыз, – дип, урыннарыннан торалар.

Акмамык аларга ни-нәрсәләр булганын сөйләп бирә. Абыйлары элеккечә таза-сау булып уянган бит инде моның, бары тик иң кечесенең генә бер сөяге табылмаганга күрә, аркасы бөкрерәк булып калган, ди.

Җиде туган элеккечә ау аулап көн итә башлыйлар. Акмамык абыйларына кәләшләр табып, аларны өйләндерә. Абыйлары, гаиләләре булгач та, сеңелләрен кадерләп кенә торалар. Аларның хатыннары, көнләшеп: «Ирләребез безне Акмамык кебек кадерләмиләр, берәр нәрсә уйлап табарга кирәк», – диешәләр, ди. Иң олы килендәш Акмамыкның бугазы белән колагына кургаш тутырырга котырта. Кече киленнәре генә Акмамыкны яклап чыккач, аны, синең бугазыңа да кургаш тутырырбыз, алайса, дип куркыталар. Акмамыкның колакларына кургаш тутырганда, кече килен аның чәнти бармагын тотып тора.

Акмамык телсез-өнсез кала бит инде, көннән-көн сула, корый башлый.

– Сеңлебезгә ни булды? – дип кайгырышкан абыйларына да берни әйтә алмый – бугаздагы кургаш сөйләшергә бирми бит.

Ахырында иң олы җиңгәсе:

– Акмамык моңая, аңа кияүгә чыгарга кирәк, – ди.

Уйлашалар да:

– Акмамыкны дөягә утыртып җибәрик, ошаткан кешесен үзе сайлар, – дигән фикергә киләләр.

Шулай эшлиләр дә. Абыйлары бер дөягә бөркәвечләр ябып, бик матур итеп бизәп, Акмамыкны матур итеп киендереп, бизәндереп утыртып җибәрәләр. Бу вакытта патша улы белән вәзир улыауга чыккан була, ерактан бер кара нәрсә күреп алалар. Якынрак барып карасалар, өсләренә бай итеп бизәлгән бөркәвеч ябылган дөя үзалдына утлап йөри, ди.

Патшаның улы:

– Өсте минеке, – ди.

Вәзирнең улы:

– Дөясе минеке, – дигән.

Күрәләр: бер дөя, дөя өстендәге бөркәнчек астында бер кашык су белән йотарлык чибәр кыз утыра. Болар:

– Әй, кызый, кешеме син, җенме син? – дип сорыйлар.

Җавап ишетелми. Телсез булса булыр, дип, патша улы аны үзенә хатынлыкка ала.

Шулай яшиләр болар. Бер уллары туа, үсә. Бу малай дүрт-биш яшьләргә җитә. Акмамык һаман сөйләшми бит инде.

Патша улы:

– Тагын бер тапкыр өйләнеп карарга кирәк, болай яшәп булмый, – дип, кәләш эзләп чыгып китә.

Акмамыкның кәефе китә, кулыннан эш төшә, тик нишләмәк

кирәк? Ипи пешерергә дип учак алдында утырганда, уйнаган җиреннән улы кайтып керә дә:

– Әни, ипи бир! – дип кычкыра.

Телсезлеге өстенә иренең тагын бер хатын алу кайгысы да өстәлгән Акмамык улын ишетми дә. Улы, аркасына төртеп, «Әни, ипи!» дию белән, Акмамыкның бугазындагы кургаш лып итеп килеп төшә. Акмамык:

– Колагыма да сук, – ди.

Улы колагына суккач, колагындагы кургашы да тәгәрәп төшә.

Шулай итеп икенче колагындагы кургашны да төшерәләр. Акмамык сау-сәламәт кешегә әверелә.

Ул арада патша улы яшь кәләш табып кайтып төшә. Бу вакытта Акмамык әйрән кайнатып утыра икән. Әйрән күтәрелеп түгелергә җиткән вакытта, яшь кәләш күреп ала да ат өстеннән:

– Бу нинди хәйран, түгелде әйрән! – дип кычкырып җибәрә.

Килеп аттан төшмәс борын ачулана башлаган киленгә Акмамык:

– Килен, бак, килен,
Килеп кермәс борын,
Үзе ияр башында,
Күзе учак катында, –

дип җавап бирә.

Патша улының хатыны сөйләшә башлавы турындагы хәбәр тирә-якка тарала. Патша улы, Акмамыкның теле ачылганын ишетеп, яшь кәләшен аттан да төшереп тормыйча, кире өенә озата.

Акмамык, туганнарын сагынып, улына алтын ашык ясата һәм җыр өйрәтә:

«Ашыгыңны аткан вакытта,
Югалган сөяк кулымда,
Акмамыкның улы мин,
Җиде абзыкаем өчен,
Төпчеге Бәйрәм өчен,
Алтын ашыгым, әйдә! –

дип әйт, ди.

Инде Акмамыкның туганнарына килик. Кече энеләре Бәйрәм: «Сеңлебезне дөягә утыртып җибәргәнгә биш ел узды, үлеме икән, тереме икән, аны табыйк, хәлен белик», – дип, абзалары җидесе җиде якка чыгып китәләр, ди. Бөкре Бәйрәм Акмамык яшәгән шәһәргә килеп чыга. Шәһәр урамнарында йөргәндә күрә бу: бер төркем малай ашык уйный, ди. Шуның берсе:

– Югалган сөяк кулымда,
Акмамыкның улы мин,
Җиде абзыкаем өчен,
Төпчеге Бәйрәм өчен,
Алтын ашыгым, әйдә! –

дип такмаклап, ашыгын ыргытып җибәргән.

Бәйрәм, энесен танып, аның янына килә дә:

– Угланчыгым, әйдә әле, өегезне күрсәт, – ди.

Акмамык – абыйсын, абыйсы Акмамыкны танып алып, бик озак сөйләшәләр, елашалар. Акмамык аңа үзенең башыннан узганнарын сөйләп бирә, кунак итә, кадер-хөрмәт күрсәтә инде.

Ике-өч көн кунак булгач, Бәйрәм өенә җыена башлый. Акмамык җиде капчык тегеп, шуның

алтысына үрмәкүч, чаян тутыра, җиденчесенә кишмиш катыш чикләвек тутырып, өстенә бәләкәй генә бер чаян малаен сала да:

– Бу капчыкларны җиңгәләремә бирерсең, ә менә монысын кече җиңгәмә бирерсең, – дип, аерып күрсәтеп, абыйсын озатып җибәрә.

Кече абыйсы кайтып җиткәч, һәрбер киленгә үз капчыгын тапшыра.

– Каенсеңлебез күчтәнәч җибәргән, – дип, җиңгәләре кулларын капчыкка тыксалар, үрмәкүч, чаяннар чагып бетерә боларны. Кече җиңгәсенә генә берни булмый: чәнти бармагын бер кечкенә генә чаян тешли дә кача. Җиңгәсенә капчыгы белән чикләвек, кишмиш тә кала.

Бәйрәм, агаларын чакырып:

– Мин Акмамыкны таптым, ул фәлән падишаһның улында кияүдә, – дип, аның хәлләрен сөйләп бирә.

Җиде туган сеңелләре өчен бик шатланалар, этиәниләрен кайтып алып, бергәләшеп, кунакка йөрешеп, бик бәхетле яшиләр, ди.

АК-ПАМЫК

Давным-давно жили-были муж и жена. Было у них семь сыновей, а вот дочери не было. Когда жене пришло время рожать, сыновья собрались на охоту и, уходя, сказали отцу:

– Если родится сестра, посадите на плетень куклу, а если брат – повесьте лук и стрелы.

Родилась девочка, и отец, как и договорились, посадил на плетень куклу. Однако злые соседи тайком сняли куклу и вместо неё повесили лук и стрелы. Возвращавшиеся с охоты братья ещё издали увидели на плетне лук и стрелы. «Бог не дал нам сестрёнку», – возроптали они и решили никогда больше не возвращаться домой.

Ушли в горы, поселились в пещере, там и жили, занимались охотой.

Пусть они пока охотятся, а вы послушайте о новорождённой.

Отец и мать назвали дочку Ак-Памык. Ждали они сыновей, день ждали, месяц, год, но от них не было никаких вестей. Тогда родители потеряли всякую надежду.

Так прошло немало лет, девочке исполнилось десять. Однажды к ним зашла соседка.

– Мне помощницы нужны, – сказала она. – Отпустишь свою дочку?

Мама согласилась:

– Пусть идёт, коли хочет.

Ак-Памык с радостью пошла к соседке.

Когда все собрались, одна из женщин произнесла:

– У кого есть братья, пусть займёт почётное место, у кого нет – пусть сядет на золу.

Ак-Памык села на золу рядом с другими девушками.

Тут одна старуха сказала:

– Поднимись с золы, козочка моя, и займи самое почётное место.

– Почему, бабушка? – спросила Ак-Памык. – У меня же нет братьев.

– Ах ты, бессовестная! – укорила её старуха. – На почётное место уселись те, у кого по одному или по два брата, а у тебя их целых семь!

Ак-Памык удивилась и сказала:

– Дожила до своих лет, а о том, что у меня есть братья, впервые слышу.

– Козочка моя! – продолжала старуха. – Твои братья живут в горах, в какой-то пещере. Мать с отцом устали их искать. Поэтому тебе и не рассказывали, боясь, что ты пойдёшь искать братьев и не вернёшься.

Ак-Памык окончила работу, вернулась домой и начала расспрашивать:

– Скажи, матушка, есть ли у меня братья?

Мать молчит, отпирается.

Ак-Памык крепко схватила её за руку, после чего мать ответила:

– Есть, доченька. Но они ушли из дома в тот день, когда ты родилась.

Ак-Памык удивлённо спросила:

– Почему вы не сказали, что у меня есть братья?

– Мы боялись, что ты пойдёшь их разыскивать и тоже не вернёшься.

Отпустив руку матери, Ак-Памык заявила:

– Я пойду искать братьев.

– Одна ты их не найдёшь, – возразила мать. – Я испеку лепёшку, она будет катиться впереди и показывать дорогу.

Мать испекла лепёшку и дала дочери. Ак-Памык взяла с собой любимого кота и пустилась в путь. Впереди катилась лепёшка, а позади бежал кот. Долго ли, коротко ли она катилась, наконец остановилась возле пещеры.

Ак-Памык осторожно вошла в пещеру. Там никого не было, на стене



висели туши газелей, а в углу была сложена грязная одежда охотников. Ак-Памык взялась за стирку, а потом начала варить мясо. Заслышав шаги возвращающихся братьев, девушка спряталась.

Войдя в пещеру, братья очень удивились: ужин приготовлен, одежда выстирана. Они переоделись, сытно поужинали и легли спать, а наутро снова ушли на охоту.

Ак-Памык опять выстирала одежду, приготовила ужин вкуснее вчерашнего и спряталась в прежнем месте.

Вечером братья вернулись и ещё больше удивились. Тогда они решили, что утром на охоту пойдут шестеро, а один останется и узнает, кто же у них хозяйничает. Так и сделали: старший из братьев остался в пещере. Однако сон быстро одолел его и он крепко уснул. Тут Ак-Памык вышла из укрытия, сделала всю работу и снова спряталась.

Пришли братья и спрашивают:

– Узнал, кто у нас хозяйничает?

Старший брат признался, что весь день проспал и ничего не видел.

На другой день оставили в пещере другого брата, но с ним случилось то же самое: он весь день крепко спал и ничего не видел. Так было со всеми братьями, пока очередь не дошла до самого младшего, которого звали Байрам.

Байрам остался в пещере, порезал себе палец и посыпал рану солью, чтобы не уснуть. Потом лёг и притворился спящим.

Спустя время появилась красивая стройная девушка и принялась за работу.

Байрам поднялся и воскликнул:

– Кто ты, джинн или человек?

– Я не джинн, я ваша родная сестра! – ответила Ак-Памык.

Байрам очень обрадовался сестре. Он помог ей приготовить ужин и пошёл встречать старших братьев. Братья очень обрадовались, когда узнали, что у них есть сестра. С тех пор они стали вместе жить-поживать: братья охотились, а Ак-Памык вела хозяйство.

Однажды Ак-Памык подметала пещеру и нашла виноградинку. Она позвала своего кота, чтобы угостить, но кот не пришёл, и она сама съела виноградинку.

Спустя время пришёл кот и стал спрашивать:

– Зачем ты меня звала?

– Я хотела угостить тебя виноградинкой, – ответила Ак-Памык.

– А где она? – спросил кот.

– Ты не пришёл, поэтому я сама съела её, – ответила Ак-Памык.

Кот рассердился и начал фыркать на очаг.

– Не гаси очаг, пожалуйста, я не смогу потом его разжечь! – С трудом ей удалось упросить кота.

На другой день Ак-Памык нашла в пещере сушёную ягоду. Она снова позвала кота, чтобы угостить, но кот не пришёл. Не удержавшись, она вновь съела ягоду.

Спустя время явился кот и спросил:

– Зачем ты звала меня?

– Я хотела угостить тебя ягодой.

– Где же она?

– Я уже съела, – ответила Ак-Памык.

Кот рассердился и с такой силой фыркнул на очаг, что сразу погасил огонь.

Ак-Памык хотела высечь огонь с помощью камня, но не смогла. Времени оставалось мало, а ужин всё ещё не сварен. Что делать? Она вышла из пещеры и увидела на дальнем склоне горы дым, который вился над чьим-то жилищем. Туда и направилась Ак-Памык. Она дошла до жилища, остановилась у порога и произнесла приветствие. Когда она вошла, то увидела страшного седого Дива.

Див ей сказал:

– Если бы ты не сказала приветствие у порога моего дома, я бы растерзал тебя, но теперь не трону. Подойди поближе, дочка, и скажи, зачем пришла.

– Я пришла просить огня.

– Ладно, дочка, – ответил он, – держи свой подол.

Он положил ей в подол крохотный тлеющий уголёк, потом стал сыпать золу. Наполнив подол девушки золой, Див вытащил из очага горящую головешку и положил сверху.

– Можешь идти, дочка, – сказал Див и отпустил Ак-Памык.

Ак-Памык так спешила домой, что даже не заметила, что уголёк прожёг в подоле дырочку, а через неё стала сыпаться зола.

Вернулись братья, поужинали и уснули, а наутро, как обычно, ушли на охоту. Сразу после этого явился Див: по рассыпанной золе он легко нашёл пещеру братьев, где жила Ак-Памык.

Див закричал:

– Отвори, дочка!

– Нет, если открою, братья будут ругаться, – ответила Ак-Памык и не отворила.

– Просунь под дверь хотя бы палец. Если не просунешь, я подстерегу твоих братьев и растерзаю.

Ак-Памык испугалась и просунула под дверь палец. Див крепко схватил палец, уколол его иголкой и принялся сосать кровь.

Насытившись, он пригрозил Ак-Памык:

– Ничего не рассказывай братьям, а то я тебя съем.

Ак-Памык от страха решила ничего не рассказывать братьям.

Див каждый день приходил и сосал её кровь.

Ак-Памык с каждым днём худела и чахла. На расспросы братьев отвечала, что с ней всё в порядке.

Братья решили выведать её тайну. Однажды они не пошли на охоту и спрятались поблизости.

Ак-Памык сделала всё по хозяйству, к приходу Дива заперла дверь изнутри.

Привыкший пить кровь Див только подошёл к двери, тут



братья выскочили из засады и набросились на него. Они отрубили ему голову. Голова покатилась так быстро, что братья, как ни старались, не могли угнаться за ней. Спустя какое-то время из этой головы выросло несколько дивов. Они вернулись к пещере, накинулись на семерых братьев, съели их, оставив одни только кости. Ак-Памык дивы не нашли: она спряталась под козьими шкурами.

Как только дивы ушли, она вышла из укрытия, собрала кости братьев и прикрыла их шкурами. Потом села на коня и помчалась в долину. Она ездила из города в город, из селения в селение и расспрашивала мудрецов, как можно оживить братьев. Но никто из них не смог ей помочь. Наконец Ак-Памык нашла старуху-знахарку и рассказала ей о своей беде.

– Дочка, – молвила старуха, – я подскажу тебе, как оживить братьев, растерзанных дивами, но это будет сложно.

– Бабушка, только скажи! Ради братьев я на всё готова.

Тогда старуха сказала:

– В степи пасётся верблюдица Ак-Мая. Если ты её молоком окропишь кости своих братьев, то они оживут. Но подоить верблюдицу ещё никому не удавалось: как завидит она человека, сразу же набрасывается на него.

Поблагодарив старуху, Ак-Памык взяла пустой бурдюк и помчалась на коне в степь на поиски верблюдицы.

По дороге она встретила верблюжонка. Он оказался детёнышем Ак-Маи. Увидев Ак-Памык, он вприпрыжку подбежал

к ней. Ак-Памык сошла с коня, почесала верблюжонка за ухом, погладила по шее и угостила колючками.

Пока верблюжонок ел, она поведала ему своё горе.

– Я помогу тебе, – сказал верблюжонок. – Но если мать увидит меня с тобой, она съест нас обоих. Ты вот что сделай: бери бурдюк, лезь ко мне под брюхо и крепко держись за шерсть. Я подойду к матери и начну сосать молоко, а ты потихоньку подставь бурдюк, и я перелью в него молоко.

Ак-Памык так и сделала. Верблюжонок подбежал к матери.

Верблюдица Ак-Мая повела ноздрями и заревела:

– Человеческим духом пахнет! – И стала бить копытами.

– Матушка, откуда в этой степи человек? – успокаивал её верблюжонок.

Ак-Мая притихла, а верблюжонок начал сосать и переливать молоко в бурдюк. Так он наполнил бурдюк и пошёл потихоньку к пригорку, за которым Ак-Памык спрятала коня.

Но Ак-Мая всё время обнюхивала воздух и следила за своим верблюжонком. Когда же она увидела, что из-под его брюха вылезла Ак-Памык и вскочила на коня, то кинулась за ней. Ак-Памык так быстро ускакала, что Ак-Мая не смогла её догнать и вернулась обратно. За непослушание она прокляла своего верблюжонка, превратив в камень.

Ак-Памык благополучно добралась до пещеры. Кости братьев были на месте, не хватало только одной косточки младшего брата Байрама. Видимо, дивы её обглодали. Ак-Памык разложила кости, окропила их молоком верблюдицы и завернула в чёрную кошму.

– Долго же мы спали! – Братья чихнули и встали целыми и невредимыми. Только младший брат Байрам ходил немного согнувшись.

Ак-Памык рассказала братьям о том, что с ними произошло.

С тех пор они стали жить-поживать лучше прежнего. Ак-Памык нашла им невест, братья женились, но сестру продолжали любить сильнее, чем своих жён.

Однажды завистливые жёны решили избавиться от Ак-Памык.

– Нужно втолкнуть ей в горло и уши свинец, чтобы она не могла ни говорить, ни слышать, – предложила жена старшего брата.

Все согласились, а жене Байрама, которая не хотела плохого Ак-Памык, они пригрозили. И когда злые жёны братьев осуществляли свой коварный план, жена Байрама держала Ак-Памык за мизинец.

Ак-Памык сделалась глухонемой и опять стала худеть и чахнуть.

Долго допытывались братья, что с ней случилось, но так и не узнали – свинец не давал ей говорить.

Тогда жена старшего брата сказала:

– Ак-Памык тоскует, ей нужно выйти замуж. Посадите её на верблюда, и пусть она идёт, куда захочет. Ак-Памык сама отыщет своё счастье.

Братья украсили верблюда вышитыми покрывалами, навьючили на него ковровые носилки, посадили в них красиво одетую сестру, и верблюд пошёл по дороге. Он спустился с гор на равнину, свернул с дороги и стал пастись. В это время в степи охотились сын падишаха и сын визиря. Сын визиря издалека увидел верблюда, который пасся без присмотра хозяина, и сказал:

– Это мой верблюд, я первый его заметил!

– Хорошо, – согласился сын падишаха. – А что находится в носилках, будет моим.

Они поскакали к верблюду и увидели, что он богато украшен, а в носилках сидит девушка дивной красоты.

– Кто ты? – обратился к Ак-Памык сын падишаха. – Человек или джинн?

Ак-Памык молчала.

Долго не думая, сын падишаха решил взять немую красавицу в жёны.



Прошли годы. У Ак-Памык родился сын, но она всё ещё оставалась глухонемой. Сын падишаха начал тосковать. «Так больше жить нельзя, надо взять вторую жену», – подумал он и пошёл искать невесту. Узнав об этом, Ак-Памык опечалилась. Работа стала валиться из рук: так и сидит весь день возле очага.

Тут к ней подошёл её малолетний сын и попросил лепёшки. Ак-Памык продолжала сидеть неподвижно и не слышала его. Тогда сын начал её тормошить:

– Матушка, я хочу кушать!

Неожиданно из горла матери выпал кусок свинца, и Ак-Памык сказала:

– Сынок, ударь меня по правому уху.

Сын исполнил её желание, и из правого уха выпал кусок свинца.

– А теперь ударь по левому, – попросила Ак-Памык.

Из левого уха тоже вывалился кусок свинца. Так Ак-Памык стала совершенно здоровой.

Через несколько дней сын падишаха возвратился с новой невестой.

В это время Ак-Памык сидела у очага и кипятила молоко.

Невеста, сидя на лошади, увидела, что молоко вспенилось, и крикнула:

– Где это видано?
Молоко уже бежит,
А жена сидмя сидит!

Ак-Памык ей в ответ:

– Видано ли это?
Невеста с лошади не слезла,
А в дом с советами полезла!

Весть о том, что жена сына падишаха – красавица Ак-Памык заговорила, дошла и до мужа. Он тут же приказал, не снимая с лошади, отвезти невесту обратно к родителям.

Для Ак-Памык наступили счастливые дни, но она не могла забыть своих братьев и скучала по ним.

Однажды она дала сыну игральную косточку и сказала:

– Если хочешь выиграть, то выучи присказку:

Съели наших братьев
Дива злые рати.
Я сдаваться не привык,
Сын я Ак-Памык.
Косточку кидаю прямо
В спину дядюшки Байрама!

Сын Ак-Памык выучил присказку и, когда играл с мальчиками, всегда приговаривал так, как учила мать.

Пусть он пока играет, а мы вернёмся к братьям.

Однажды, когда братья вернулись с охоты, младший брат Байрам сказал:

– Пять лет прошло с тех пор, как мы отправили сестру искать счастье. Жива ли, здорова ли, давайте разыщем её, если вдруг попала в беду, поможем ей.

Все согласились с Байрамом и разъехались в разные стороны на поиски сестры.

Байрам приехал как раз в тот город, где жила Ак-Памык. Прогуливаясь по городу, он увидел мальчиков, игравших в кости. Один из них, бросая косточку, приговаривал:

Съели наших братьев
Дива злые рати.
Я сдаваться не привык,
Сын я Ак-Памык.
Косточку кидаю прямо
В спину дядюшки Байрама!



Так Байрам узнал своего племянника и сказал:

– Веди меня, племянничек, в дом, к своей матери.

Как только Байрам переступил порог дворца, навстречу вышла Ак-Памык. Они, узнав друг друга, долго плакали. Ак-Памык рассказала про все свои беды.

Погостив два-три дня, Байрам начал собираться домой. Провожая брата, Ак-Памык собрала гостинцы невесткам. Наполнив шесть мешков пауками и скорпионами, она сказала:

– Отвези эти мешки в подарок моим старшим золовкам и раздай каждой по мешку.

Наполнив изюмом и орехами и положив наверх маленького скорпиона, она вынесла седьмой мешок и сказала:

– А этот мешок отдай своей жене.

Байрам вернулся домой, раздал подарки жёнам братьев, а последний мешок отдал своей жене.

Жёны братьев обрадовались гостинцам, которые послала им Ак-Памык, и каждая поторопилась поскорей запустить руку в свой мешок. В мешках было полно пауков и скорпионов. Они изжалили их до полусмерти.

Когда жена Байрама запустила руку в свой мешок, там оказался маленький скорпион, который слегка ужалил её в мизинец и уполз. Тут жена Байрама принялась есть изюм с орехами.

Пусть она пока ест, а вы послушайте конец сказки.

Позвав братьев, Байрам поведал им о сестре:

– Я нашёл Ак-Памык, она вышла замуж за сына падишаха.

Братья были очень рады за сестру. Разыскали и привезли родителей к ней во дворец. С тех пор жили долго и счастливо.





Литературно-художественное издание
Для детей среднего и старшего школьного возраста

АК-ПАМЫК

Туркменская народная сказка

Казань. Татарское книжное издательство. 2016
На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма
Урта һәм өлкән яшьтәге мәктәп балалары өчен

АКМАМЫК

Төрекмән халык әкияте

Мөхәррирләре *А. Ф. Галиәхмәтова, Э. Р. Хөснетдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т. В. Гредюшко*
Корректорлары *А. Р. Миңнуллина, Д. З. Шәмсетдинова*

12 + Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436–ФЗ.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.07.2016. Форматы 84×100 1/16.
Шартлы басма табагы 3,9. Тираж 2500 д. Заказ М-1765.

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:

Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Маркетинг бүлеге:

Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-кибет:

http://www.tatkniga.ru

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Кадерле укучылар!

Татарстан китап нәшрияты чыгарган әлеге китаплар да күңелегезгә хуш килер дип уйлыйбыз.

Дорогие читатели!

Надеемся, что вам понравятся новинки Татарского книжного издательства.



9 785298 031745